**РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН**
**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ РЫБНО-СЛОБОДСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**
**МУНИЦИПАЛЬНОЕ КАЗЕННОЕ УЧРЕЖДЕНИЕ «ОТДЕЛ ОБРАЗОВАНИЯ»**
Переулок Больничный, дом 6,
пгт. Рыбная Слобода, 422650

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**БАЛЫК БИСТӘСЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
**«МӘГАРИФ БҮЛЕГЕ» МУНИЦИПАЛЬ КАЗНА УЧРЕЖДЕНИЕСЕ**
Хастаханә тыкрыгы, 6 нчы йорт,
Балык Бистәсе штп., 422650

Тел.: (8-84361) 2-21-92, факс: (8-84361) 2-21-26. E-mail: sloboda.ege@rambler.ru, sloboda.filial@mail.ru

**Балык Бистәсе муниципаль районы муниципаль бюджет гомуми белем бирү учреждениесе “Яңа Арыш урта гомуми белем бирү мәктәбе” укытучысы Галимова Гүзәлия Наил кызының педагогик эшчәнлегенә бәяләмә.**

Галимова Гүзәлия Наил кызы - районның татар теле һәм әдәбияты укытучылары арасында нәтиҗәле эшчәнлеге белән үз урынын билгеләгән укытучы. Педагог укыту-тәрбия эшен укучыларның иҗади үсешенә, мөстәкыйльлегенә, шәхси үзенчәлекләренә игътибар итеп оештыра. Гүзәлия Наилевна дәресләре кызыклы, бай эчтәлекле һәм заманча технологияләргә корылган булуы белән аерылып тора. Аның максаты - укучыларга туган телне, әдәбиятны тирәнтен өйрәтү, халкыбызның бай рухи мирасын пропагандалау, балаларда милли үзаң, горурлык хисләре булдыру һәм, иң мөһиме, һәрьяктан тулы үсеш алган, әхлаклы шәхес тәрбияләү.

Ул - үз фәнен югары дәрәҗәдә укучыларына җиткерә алучы тәҗрибәле педагог. Аның укучылары фән буенча яхшы белем күрсәткечләренә ия, 2015-2016 уку елында тапшырылган ТДИ нәтиҗәләре буенча укучыларының күрсәткечләре – 3,7 балл. БРТ нәтиҗәләре - 4,2 балл булды. Ә 2016-2017 уку елында тапшырылган ТДИ нәтиҗәләре буенча –4,25 балл, БРТ нәтиҗәләре буенча - 4,56 баллны тәшкил итте. Ул укыткан сыйныфларда сыйфатлы өлгереш 93 % .

Муниципаль һәм республика күләмендә фән буенча олимпиадаларда Гүзәлия Наил кызы укучылары уңышлы катнаша. Соңгы 3 елда аның укучылары муниципаль этапта 7 тапкыр җиңүче булды һәм 3 призлы урынны алды. 2018-2019 уку елында 11 сыйныф укучысы Галимова Энҗе татар теле фәненнән Республика олимпиадасының йомгаклау этабында катнашты. Район күләмендә үткәрелгән “Татар кызы” конкурсында аның укучысы Валеева З. “Сөйкемле кыз” номинациясе буенча җиңүгә лаек булды.

Галимова Г.Н. укучылары өстәмә уку белән кызыксыналар, татар журналларын яратып укыйлар. Укытучы укучылар белән сыйныфтан тыш эшчәнлеккә зур игътибар бирә. Ел саен укучылар белән фәнни-гамәли конференцияләрдә катнаша, призлы урыннар ала. Бу юнәлештә соңгы елларда ирешкән нәтиҗәләре түбәндәге:

- XI Республикакүләм Ибраһим Хәлфин исемендәге укучыларның фәнни-эзләнү конференциясендә катнашучы шаһәдәтнамәсе (Гимадиева Р., 9 кл.);
- «Билет в будущее» дип аталган Республикакүләм иншалар конкурсының 1 этабында «Эшче династиясе» номинациясендә 2 дәрәҗәдәге диплом (Гимадиева Р., 9 кл.);

- Республикакүләм Гамил Афзал исемендәге иҗат фестивале лауреаты дипломы (Валеева С., 5 кл);

- Татарстан Республикасы Мәгариф һәм фән министрлыгы оештырган “Илһам” бөтенроссия яшь язучылар бәйгесендә II дәрәҗә диплом ( Галимова Э., 9 кл);

- “Әхмәт Гадел укулары” Республикакүләм фәнни-гамәли конференциясендә лауреат дипломы (Гимадиева Р., 11 кл.);

-“Җәлил укулары” халыкара шигърият конкурсы муниципаль этабы мактау кәгазе (Галимов Данияр, 2 урын);

-“Җәлил укулары” халыкара шигърият конкурсы муниципаль этабы мактау кәгазе (Валеева Сәйдә, 1 урын);

Галимова Гүзәлия Наил кызы - үзенең методик тәҗрибәсе белән мәктәп, район һәм республика күләмендә уртаклаша: ачык дәресләр күрсәтә, семинар һәм киңәшмәләрдә, һөнәри бәйгеләрдә чыгышлар ясый. Ул “Ел укытучысы-2016” Бөтенрәсәй бәйгесенең муниципаль этабында лауреат, “Ел сыйныф җитәкчесе - 2018” Бөтенрәсәй бәйгесенең муниципаль этабында лауреат булды. Шулай ук “Ел укытучысы-2019” Бөтенрәсәй бәйгесенең муниципаль этабында актив катнашуы өчен рәхмәт хатына лаек булды. Тырыш, үзенә һәм хезмәттәшләренә карата таләпчән, җаваплы укытучыны барлык хезмәттәшләре хөрмәт итә.

Югары әйтелгәннәрдән чыгып, Галимова Гүзәлия Наил кызы татар теле һәм әдәбияты укытучыларының "Туган тел" мастер-класс бәйгесендә катнашырга лаек дип табылды.

Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының “Мәгариф
бүлеге” муниципаль казна
учреждениесы башлыгы: И.М.Садиков